**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАЛАНЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ IV ЧАКЫРЫЛЫШ XXVIII УТЫРЫШЫ**

**К А Р А Р № 54**

**Баланлы ав.** **16 май 2023 ел.**

**«Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баланлы авыл җирлеге Советы депутаты статусы турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2022 елның 29 августындагы 42 номерлы Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы N 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баланлы авыл җирлеге Советы **КАРАР ЧЫГАРДЫ**:

1. «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Баланлы авыл җирлеге депутаты статусы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2022 елның 29 августындагы 42 номерлы Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баланлы авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 статьяның 3 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 18 статьяның 1 пунктының б пунктчасында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баланлы авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы: И.Х.Гыйлфанова